Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Кышлау авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

9 март 2019 ел № 85

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Советының 2014 елның 10 ноябрендәге 87 номерлы «Физик затларның милкенә салым турында» карарына үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Кышлау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Советының 2014 елның 10 ноябрендәге 87 номерлы «Физик затларның милкенә салым турында» карарының (2015 елның 3 июнендәге 113 номерлы, 2015 елның 19 октябрендәге 4 номерлы, 2018 елның 2 июлендәге 70 номерлы карарлары басмасында), 4 нче бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге бүлекчәләр өстәргә:

«4.1. Физик затлар милкенә салым түләүдән азат ителә:

4.1.1. 18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнар;

4.1.2. әлеге пунктның 4.1.1. булекчәсендә күрсәтелгән гражданнарның балигъ булмаган балалары.

4.1.3. инвалид балаларның ата-аналары (уллыкка алучылар, опекуннар, попечительләр), тулы дәүләт тәэминаты булган балалардан тыш.

Салым ташламасы салым салу объектларының түбәндәге төрләренә карата бирелә:

1) фатир, фатирның бер өлеше яки бүлмә;

2) торак йорт яки торак йортның бер өлеше.

Салым ташламасы гаиләгә туры килә торган салым салуның салым түләүченең теләге буенча бер объектына карата бирелә.

Салым ташламасы Кышлау авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче салым түләүчеләр тарафыннан салым түләүче милкендә булган һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган салым салу объектына карата салым суммасын түләнергә тиешле күләмдә бирелә.

Салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым ташламаларына хокукы булган физик затлар салым органына салым

ташламаларын бирү турында гариза бирергә, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документларны тапшырырга хокуклы.

Салым ташламасына хокукны раслаучы документлар булып түбәндәгеләр тора: әлеге салым буенча салым түләүче дип танылган физик затның шәхесен таныклаучы документ, шулай ук аның исеменә бирелгән күп балалы гаилә таныклыгы, яисә өч һәм аннан күбрәк бала туу турында таныклыгы булган ата-аналар (уллыкка алучылар).

Салым ташламасы бирелә торган салым салуның сайланган объектлары турында хәбәрнамә салым түләүче тарафыннан салым чоры булган һәм аннан башлап күрсәтелгән объектларга карата салым ташламасы кулланыла торган елның 1 ноябренә кадәр үзе теләгән салым органына тапшырыла.

2. Әлеге карар районның «Әтнә Таңы» газетасында бастырыла, мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә: http://atnya.tatarstan.ru веб – адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырыла.

3. Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Кышлау авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Шакирова